# ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ (КАРАР)

## Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Балтач шәһәр җирлеге Балтач шәһәр тибындагы поселогы

2020 елның 20 ноябре №2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Балтач шәһәр җирлегенең Балтач шәһәр тибындагы поселогында гражданнар җыены карар итте:

1. Балтач шәһәр җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булмаган баладан 2021 елда, Бөек Ватан сугышы ветераннарының 1 нче төркеме инвалидларыннан тыш, 500 сум күләмендә үзарасалым кертергә.

2. Алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкару өчен җибәрергә:

- Балтач шәһәр тибындагы бистәсендә: Ленин, Киров, Нариман урамнары буенча асфальт-бетон өслекле җәяүлеләр тротуарлары урнаштыру; Ибраһимов урамы буенча күперне капиталь ремонтлау; Ленин урамы буенча җәяүлеләр күперләрен капиталь ремонтлау; Үзәк урамда һәм паркларда ике дәүләт телендә элмә librтакталар урнаштыру.

3.Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Балтач шәһәр җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырырга, Балтач муниципаль районының рәсми сайтында baltasi.tatarstan.ru халыкка игълан итәргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Балтач муниципаль районы

Балтач шәһәр җирлеге башлыгы Р.Р.Нотфуллин